Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № №XXVII-4**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 17 гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы И.Г. Вәлиевның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсендәге 6 өлешенең 2 пункты, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 маддәсендәге 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 41 маддәсендәге 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Вәлиев Илһам Госман улының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы вазыйфасыннан үз теләге белән отставкага китүен кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы Вәлиев Илһам Госман улының вәкаләтләре 2018 елның 17 гыйнварыннан вакытыннан алда туктатылган дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов